

# ЧИШМӘ БАШЫ

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының «Арча 8нче балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе

№8 2026ел
апрель

***Ата –аналар һәм балалар өчен мәгълүмати-таныш белү газетасы***

- ***Апрель ае — Тукай ае, ЯҢАЛЫКЛАР***
- ***Тукай яши безнең куңелләрдә***
- ***Яшь экологлар - табигатьне саклаучылар***
- ***МӘКТӘПТӘ ФУТБОЛ***
- ***Әти, әни, мин – футбол гаиләсе***
- ***Әкиятләр дөньясында***
- ***Ачык дәрес***

*Апрель ае — табигать уянуы, кояшлы көннәр һәм гөрләвекләр вакыты. Бу ай шулай ук татар халкының бөек шагыйре Габдулла Тукай туган ай буларак та кадерле*






***Апрель ае — Тукай ае,***
***Шигырьләр агыла.***
***Бөек шагыйрьне искә алып,***
***Халык җыела.***
***Туган телне зурлап,***
***Шигырьләрен укыйбыз.***
***Тукай рухына баш иеп,***
***Чәчәкләр салабыз.***

Габдулла Тукай
Туган тел

И туган тел, и матур тел, әткәм-әнкәмнең теле!
Дөньяда күп нәрсә белдем син туган тел аркылы.

Иң элек бу тел белән әнкәм бишектә көйләгән,
Аннары төннәр буе әбкәм хикәят сөйләгән.

И туган тел! Һәрвакытта ярдәмең белән синең,
Кечкенәдән аңлашылган шатлыгым, кайгым минем.

И туган тел! Синдә булган иң элек кыйлган догам:
Ярлыкагыл, дип, үзем һәм әткәм-әнкәмне, ходам!

# ЯҢАЛЫКЛАР



• Роуп-скиппинг-скакалка аша сикерү. 7 апрель көнне Кукмара муниципаль районының «Ялкын» яшьләр үзәге базасында республикада күптән түгел генә аерым төр буларак аккредитацияләнгән әлеге спорт төре буенча "Прык-скок, скакалочка" республика спорт ярышлары узды. Ярышларда мәктәпкәчә мәгариф учреждениеләреннән 18 дән артык команда катнашты. Балалар өч номинация буенча ярыштылар: эстафета 2 шәр 30 секунд ике аякта сикерү, эстафета 2 шәр 30 секунд озын сикерү ике аякта сикерү, «кармак»хәрәкәтчән уены. Заһидуллин Нариман һәм Мостафина Айзиләдән торган балалар бакчасы командасы " Иң җитез команда «номинациясендә җиңүче булды.



• "Бәхет биргән туган җирем" Бүген Яңа Кенәр урта мәктәбе базасында РСФСРның атказанган укытучысы, Бөек Ватан сугышы ветераны Рәгыйп Усман улы Халитов исемендәге укучылар һәм укытучыларның “Бәхет биргән туган җирем” XII төбәкара фәнни-гамәли конференциясе булып узды. Безнең бакчабыздан Шакирова Гөлгенә Мөсәвир кызы (I урын) һәм Мустафина Алина Рөстәм кызы ( III урын) катнашып, җиңүләр белән кайттылар.



• Зурлар төркемендә тәрбияләнүче Фәрхуллин Булат һәм Мостафина Айзилә мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен республика олимпиадасында катнашып, 1 урынны яуладылар.



• Арча муниципаль районы «Арча 7 нче балалар бакчасы» базасында «Шигъриятнең якты йолдызы» дип аталган районкүләм шигырь уку бәйгесе булып узды. Бакчабыздан Абдуллина Диләрә Г.Тукайның "Бичара куян" шигыре белән чыгыш ясады һәм 1 нче урынга лаек булды.



23 апрель көнне Арчаның 1 нче номерлы балалар бакчасында Бөек татар шагыйре Габдулла Тукайга багышланган "Туган телем - иркә гөлем" исемле районкүләм шигырь сөйләүчеләр бәйгесе узды. Конкурста 3-4 яшьлек балалар катнаштылар. Безнең бакчабыздан уртанчылар 1, 2 төркемендә тәрбияләнүче Әгъзәмова Айгизә һәм Ишмурзина Язилә "Фатыйма белән Сандугач" шигырен сәхнәләштереп сөйләп 1 урынга лаек булдылар.



Арча 9 нчы балалар бакчасында бөек татар шагыйре Г.Тукайның тууына 140 ел тулуга багышланган "Тукай әкиятләре буйлап" девизы астында үткәрелгән республикакүләм "Китапнамә" бәйгесенә йомгак ясалды. Безнең бакчадан Шакирова Гөлгенә Мөсәвир кызы катнашып, 1 урынга лаек булды.

# ЯҢАЛЫКЛАР




• Бакчабызның яшь артистлары Ләйлә Хөсәен кызы һәм Гөлназ Мансур кызы җитәкчелегендә район күләмендә үткәрелгән "Яшь биючеләр" бәйгесендә катнашып, 1 урынны алдылар.



Безнең балалар бакчасы педагоглары Алеева Ләйлә Хөсәен кызы, Диярова Гөлназ Мансур кызы һәм Шәрипова Алсинә Хаҗияхмәт кызы " Бөек елларга баш иябез..." Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 81 еллыгына багышлап, Арча муниципаль районы мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе педагоглары арасында 2 урынны яуладылар.



• 30 нчы апрель көнне Арчаның үзәк китапханәсендә "Без Тукай варислары" - Мы
наследники Тукая" дип исемләнгән район бәйгесе булып узды. Безнең балалар бакчасыннан зурлар төркемендә тәрбияләнүче Абдуллина Диләрә "Г.Тукайның әсәрләрен сәнгатьле сөйләү номинациясендә чыгыш ясады. Конкурсның нәтиҗәләрен көтеп калабыз.





# Тукай яши безнең куңелләрдә



Бөек татар шагыйре Габдулла Тукайның туууына 140 ел тулу уңаеннан бакчабызда тәрбияләнүчеләр арасында уздырылучы «Тукай безне күңелләрдә» дип исемләнгән әсәрләрне сәхнәләштерү бәйгесе узды. Нәни артистларыбыз бөек Тукаебызның "Бала белән күбәләк", "Эш беткәч уйнарга ярый", "Кәҗә белән Сарык" әсәрләрен сәхнәләштерделәр. Шулай ук Г.Тукайның тормыш юлын сәхнәләштерделәр. Балалар бик тырышып әзерләнгән иде.

















• Безнең балалар бакчасында бөек татар шагыйре Габдулла Тукайның тууына 140 ел тулуга багышланган, тәрбияләнүчеләр һәм аларның ата-аналары арасында "Шүрәле дуслары белән" дигән уртак кул эшләре конкурсы уза. Анда кемнәр генә юк иде: Шүрәле дә, Су анасы да, аның әкиятләренең башка таныш геройлары да.
Ә иң мөһиме – ата-аналар балалар белән бергә үзләренең иҗади сәләтләрен ачтылар. Кул эшләре өчен төрле материаллар кулландылар. Балаларны һәм әти-әниләрне бергәләп башкарылган эш кебек бернәрсә дә якынайтмый.

• Арча үзәк китапханәсендә безнең балалар бакчасы педагогик коллективы һәм китап укучылар белән берлектә 2026 елда Бөек татар шагыйре Габдулла Тукайның тууына 140 ел тулу уңаеннан, Татарстанда «Тукайны бергәләп укыйбыз. Читаем Тукая вместе» дип исемләнгән республикакүләм проекты кысаларында Габдулла Тукайның «Шагыйрь» - «Поэт» шигыре белән таныштык.
Чарада шигырьне татар һәм рус телләрендә укып анализ ясадык. Габдулла Тукайның тормыш юлы, иҗаты белән бәйле аз билгеле булган мәгълүматлар белән таныштык.















• Безнең балалар бакчасында бөек татар шагыйре Габдулла Тукайның тууына 140 ел тулуга багышланган «Без - Тукай варислары» исемле шигырь сөйләүчеләр бәйгесе булып узды. Бу бәйгедә бакча-бызның барлык төркемнәр дә катнашты. Балалар матур, сәнгатьле итеп Габдулла Тукайның шигырьләрен сөйләделәр, сәхнәләштерделәр. Һәр бала урынга лаек булды!



# Тукай яши безнең күңелләрдә



• 24 апрельдә Арча 8нче балалар бакчасында бөек татар шагыйре Габдулла Тукайның тууына 140 ел булуны бәйрәм итү уңаеннан "Чишмәне коткарырга кирәк" исемле экологик әдәби-музыкаль кичә узды. Бакчада тәрбияләнүче 55 бала Гали һәм аның дуслары Акбай, Кәҗә, Күбәләк белән урмандагы чишмәне коткардылар, аны ташлардан чистарттылар, Су анасына ярдәм иттеләр. Бу эшкә Шүрәле дә бик теләп кушылды. Балалар эш беткәч кенә уйнарга ярый икәнлеген дә расладылар. Кичә Габдулла Тукай шигырьләре, аның әсәрләрен сәхнәләштерү эпизодлары, сүзләренә язылган җырлар белән үрелеп барды һәм татар халкының гимнына әверелгән "Туган тел"не күмәк башкару белән тәмамланды. Бу чарада "Ашыт" дәүләт табигый тыюлыгы белгече Абдрахманова Гөлнара Ильясовна да катнашты һәм балаларны Габдулла Тукай иҗатын өйрәнүне дәвам итәргә чакырды, чөнки аның күпчелек әсәре табигатьне яратырга, сакларга өнди.

















• Безнең бакчабыз педагоглары Дөньякүләм "Татарча диктант" акциясендә катнаштылар. Быел ул бөек татар шагыйре Г.Тукайның 140 еллыгына багышланды. Акциянең төп максаты – татар теленә һәм мәдәниятенә игътибар җәлеп итү, дөнья буенча таралып яшәгән татарларны берләштерү, тел белемен тикшерергә мөмкинлек бирү, әдәби татар телен кулланучыларның даирәсен арттыру һәм татар теленә карата мәхәббәт уяту.
Без Г.Тукайның " Бәхет" хикәясе буенча диктант яздык. Бакчабыздан барлыгы 26 кеше язды.

• 27 нче апрель көнне бакчабызда "Милли кием" көне билгеләп үтелде. Балалар да, тәрбиячеләр дә милли кием элементларын кулланып киенеп килделәр. Безнең тәрбияләнүчеләр Габдулла Тукайның 140 еллыгы уңаеннан күп кенә конкурсларда катнаштылар һәм аларны котлау тантанасы булды. Аннары балалар "Түбәтәй", " Капкалы" кебек милли уеннар уйнадылар. Әлеге көн бәйрәм рухында үтте.









# Яшь экологлар - табигатьне саклаучылар

2025-2026 нчы уку елына балалар бакчасының мәктәп белән дәвамчанлык планы нигезендә бакчабызда Арча 8 нче һәм 11 нче балалар бакчаларының мәктәпкә әзерлек төркемнәрендә тәрбияләнүчеләр һәм Арча 2 нче номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбенең беренче сыйныф укучылары катнашында "Яшь экологлар - табигатьне саклаучылар" исемле экологик викторина уздырылды.Чарага балаларның табигать, анда үз-үзеңне тоту кагыйдәләре һәм экологик проблемалар турындагы белемнәрен тикшерүгә юнәлдерелгән төрле бәйгеләр һәм биремнәр кертелгән иде. Викторинада катнашучы 58 баланың белемнәрен мәртәбәле жюри - "Ашыт" дәүләт табигый тыюлыгы белгечләре Абдрахманова Гөлнара Ильясовна һәм Хурамшина Талия Талгатовна бәяләде. Бәйрәм бик дустанә, күңелле атмосферада узды. Балалар актив катнаштылар һәм экология темасына зур кызыксыну күрсәттеләр. Катнашучыларга грамоталар, медальләр һәм истәлекле призлар тапшырылды.









# МӘКТӘПТӘ ФУТБОЛ

"Мәктәптә Футбол" Бөтенроссия чарасы кысаларында безнең балалар бакчасында зурлар һәм әзерлек төркемнәре балалары өчен мавыктыргыч футбол викторинасы узды. Викторина футбол турында кызыклы сораулар һәм биремнәр белән тулы иде. Балалар викторинада бик теләп катнаштылар, үзләренең белемнәрен һәм футболга булган мәхәббәтләрен күрсәттеләр.









# Әти, әни, мин – футбол гаиләсе

«Мәктәптә Футбол " Бөтенроссия фестивале кысаларында «Әти, әни, мин – футбол гаиләсе!». Ярышларда әзерлек төркеме балалары һәм аларның ата-аналары катнашты.
Бу мавыктыргыч ярышның барлык этаплары да киеренке көрәштә узды. Бәйрәм атмосферасы бөтен нәрсәдә дә сизелә иде. Гаилә командалары җитезлек, чыдамлык, тизлек, көч буенча ярыштылар. Җанатарлар һәм тамашачылар вакыйгалар барышын күзәттеләр һәм бик «каты борчылдылар».
Әниләр дә, әтиләр дә мавыгып йөгерделәр, сикерделәр, балаларча җиңүләргә шатландылар. Ә балалар ата-аналары өчен сөенеп тордылар. Ата – аналар өчен балаларның уңай хис-кичерешләре, аларның бәхетле йөзләре-иң әһәмиятле бүләк.
Спорт-гаилә бәйрәме бер сулышта узды. Бу ярышлар балаларның һәм ата-аналарның көч сынавы гына түгел, ә һәр команданың бердәмлегә күрсәткече дә булды.










# Әкиятләр дөньясында

«Могҗизалы әкиятләр» проектын гамәлгә ашыру кысаларында укытучы-логопед Шәрипова А.Х. зурлар төркемендә тәрбияләнүчеләре белән «Әкиятләр дөньясында»дип аталган яраткан әкият турындагы монологик чыгыш конкурсы үткәрде. Балалар тырышып әзерләнгәннәр һәм яраткан әкиятләре турында сөйләделәр. Чара азагында чыгыш ясаучыларга грамоталар һәм зур булмаган бүләкләр тапшырылды.








# Ачык дәрес



«Могҗизалы әкиятләр» проектын гамәлгә ашыру кысаларында ата-аналар катнашында безнең балалар бакчасында ачык дәрес үткәрелде. Ачык дәрестә сулыш алу, артикуляцион гимнастика ясарга өйрәнделәр, кулларның вак моторикасын үстерүгә, игътибар һәм хәтерне үстерүгә күнегүләр ясадылар. Ата-аналар үзләрен кызыксындырган сорауларга җаваплар алдылар.







*Баш мөхәррир -- татар теленә өйрәтү буенча тәрбияче: Кәримова Гүзәл Рафаил кызы*
*Мөхәррир урынбасары - логопед Шәрипова Алсинә Хаҗиәхмәт кызы*